ГЛАВА
УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

с. Татарское Утяшкино, 428186
ул. Центральная, д. 10

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы, 423186

тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65, Ut.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «6» октябре № 3

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегенең Бакташ авылында гражданнар җыенын билгеләү турында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 23 октябрендә 10.00 сәгатькә Кояш урамындагы 9 нчы йорт янында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегенең Бакташ авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен татар Әдәмсә авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен вакытлыча билгеләр буенча башкарырга.

3. Гражданнар җыены этапларын үткәрүне һәм оештыруны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы тәэмин итә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегенең Бакташ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы Сез? Татарстан Республикасы Кораллы көчләренең контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләреннән, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк затлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүдән тыш:

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

(материаллар сатып алу, мәйданчык урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)».

«ӘЙЕ» «ЮК»».

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://novosheshminsk.tatarstan.ru, мәгълүмат стендында Бакташ авылы, Кояшлы урамы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы 7-нче номерлы йорт янында гражданнар җыены уздырылганчы 10 көннән дә соңга калмыйча

6. Әлеге карар аның басылып чыгуыннан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы

А.И. Нәҗметдинова